ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның «30» октябреннән № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылындагы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылында Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү өчен башка урыннар) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

3. Өргәнче авылының Зирекле авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге сайтта бастырып чыгарырга: http://novosheshminsk. tatarstan.ru/, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo. tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов